**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.10.2018 г.Казань № 137 од

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, боерам:

1. Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен тайпылышсыз үтәргә.

3. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге Боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының “Татарстан Республикасы рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге Боерыкны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырырга.

5. Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлегенә Регламентны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 10 сентябрендәге 729 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр реестрына кертү өчен юллауны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары А.Г. Галимовка йөкләргә.

Министр Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
юстиция министрының
26.10.2018 елдагы
№ 137 од боерыгы белән
расланган

# СОЦИАЛЬ ОРИЕНТЛАШКАН КОММЕРЦИЯЛЕ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН ИҖТИМАГЫЙ ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ БИЛГЕЛӘНГӘН КРИТЕРИЙЛАРГА ТУРЫ КИЛҮЛӘРЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘЛӘР БИРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан шәһ., Кремль ур., 16 йорт.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала көн саен, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга 9.00 дән 16.45 кә кадәр, төшке аш вакыты 13.00 дән 13.45 кә кадәр.

Мөрәҗәгатьләр дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга 9.00 дән 16.45 кә кадәр кабул ителә.

Җәмәгать транспорты белән “Университет” тукталышына кадәр килергә:
10, 10а, 30, 35, 35а, 54, 63, 91 нче автобуслар;
2, 3, 5, 7, 8 нче троллейбуслар.

Бинага керү пропуск яки шәхесне ачыклаучы документ буенча.

1.3.2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге (алга таба – Бүлек) телефоннары:(843) 292-26-96; (843) 223-02-13.

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә(алга таба – “Интернет”) рәсми сайты адресы http://minjust.tatarstan.ru, электрон почта адресы: minjust@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы, шулай ук Министрлык урнашкан урын һәм аның эш графигы турындагы мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында текст рәвешендәге мәгълүматны эченәалган һәм Министрлык биналарында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендларыннан;

2) “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://minjust.tatarstan.ru);

“Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы” республика дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru);

“Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәй порталы”федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язма рәвештә (шул исәптән электрон документ форматында ) мәрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат Бүлек хезмәткәрләретарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлык биналарындагы мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында дәүләт хезмәте күрсәтү турында әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (РоссияФедерациясенең законнар җыелмасы, 1995, № 48, 4563 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - 181-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон (РоссияФедерациясенең законнар җыелмасы, 1996, № 3, 145 бит)(алга таба - 7-ФЗ номерлы Федераль закон);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыелмасы, 2010, № 31, 4179 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - № 210-ФЗ номерлы федераль закон);

2011 елның 6 апрелендәге “Электрон имза турында” 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыелмасы, 2011, № 15, 2036 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба –63-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” № 601 номерлы Указы (Россия Федерациясенең законнар җыелмасы, 2012, № 19, 2338 бит (алга таба - № 601 номерлы Указ);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары (РоссияФедерациясенең законнар җыелмасы, 2016, № 45, 6261 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - 1096 номерлы карар);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерцияле булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүчеләр реестры турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары (РоссияФедерациясенең законнар җыелмасы, 2017, № 6, 937 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)(алга таба– 89 номерлы карар);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 22 февралендәге “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сораулары” № 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгы турындагы нигезләмәсе («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2006, № 10, ст. 0272, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 68 номерлы карары белән расланан Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” № 880 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары) («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы «Татарстан Республикасында социаль ориентлашкан коммерцияле

булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 681 номерлы карары (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru, 2018, 31 августа) (алга таба– 681 номерлы карар).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

иҗтимагый файдалы хезмәт–түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдә булышлык итү;

гариза бирүче – дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап телдән, язма рәвештә яки

электрон формадагы гариза белән мөрәҗәгать итүче социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма (аларныңвәкаләтле вәкилләре);

техник хата - Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча бәяләмәдәге (алга таба – бәяләмәдәге) яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белешмәдәге мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәвенә китерә торган хата(хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) шәһәр яки авыл җирлегендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыруның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә булдырылган һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль нигезләнгән структур бүлекчәсе (офис).

Башка төшенчәләр һәм терминнар 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кулланылалар.

2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Стандартка таләп эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәте атамасы | Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү | 681 номерлы карарның 2 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларны иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар итеп тану турында карар кабул итүнең 89 номерлы карар белән расланган кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр), 681 номерлы карарның 2 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Кагыйдәләргә 2 нче кушымта нигезендәге формадагы бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә нигезләнгән белешмә | Кагыйдәләрнең 5, 7, 8 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4.Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дәисәпкә алып, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты | Гариза язучының бәяләмә бирүне сораган гаризасы кергән көннән алып 30 көн эчендә.<br>Әлеге вакыт, Министрлык тарафыннан Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә запрослар җибәрелгән очракта, озайтылырга да мөмкин, әмма 30 көннән дә артыграк вакытка түгел.<br>Әлеге карарны кабул итү срогын озайту турында Министрлык гариза язучыны бәяләмә бирү турында оешмадан гариза кергән көннән алып 30 көн эчендә искәртә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән каралмаган. | Кагыйдәләрнең 6, 9 пунктлары |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү | а) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза);<br>б) гамәлгә кую документлары күчермәләре;<br>в) гариза гариза язучы вәкиле тарафыннан бирелгән очракта, гариза язучы вәкиленең гариза язучы исеменнән гамәлләр кылу вәкаләтләрен раслаучы ышаныч кәгазе.<br><br>Гариза язучы тарафыннан оешма күрсәтә торган хезмәтнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүен | Кагыйдәләрнең 5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны тәкъдим итү тәртибе; | нигезләүче документлар бирелергә мөмкин (белешмәләр, характеристикалар, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советлар бәяләмәләре һәм башкалар).<br>Гариза язучы тиешле иҗтимагый файдалы хезм буенча социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелг булса, гариза язучы тарафыннан күрсәтелә торга хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсә сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына тур килүен нигезли торган өстәмә документлар бирү тал ителми. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар вәкаләтендә булучы һәм гариза бирүче аларны тәкъдим итү хокукына ия | Гариза язучы документлар тапшырган айның беренче числосына салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе зконнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминләү кертемнәре, пенилар, штрафлар, процентларны түләү буенча үтәлмәгән вазыйфалар булмавын, оешманың намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавын раслаучы документлар<br>Гариза бирүче тарафыннан югарыда әйтелгән мәгълүматларны эченә алган документларның бирелмәве дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүчедән таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, | Кагыйдәләрнең 6 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| булган докуменларның тулы<br>исемлеге, шулай ук гариза<br>бирүченең аларны алу<br>ысуллары, шул исәптән<br>электрон формада да, аларны<br>тәкъдим итү тәртибе; | муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм җирле үзидарәнең башкару-бүлү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башка органнары (алга таба – җиле үзидарә органнары) яки дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булган, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә башкарма хакимиятнең федераль органнары, дәүләтнең бюджеттан тыш фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнарына туры килгән рәвештә катнашучы оешмалар карамагында булган, шулай ук җирле үзидарә органнары карамагында булган документларны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлештә каралган документлардан тыш;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда җитешмәүләре һәм (яки) дөрес түгеллекләре күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тәкъдим ителү, түбәндәге очраклардан кала:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны беренче тапкыр биргәннән соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы булган норматив хокукый актлар таләпләрен үзгәртү;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризада һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң бирелгән һәм алдарак бирелгән документлар исемлегенә кертелмәгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларда хаталар булу;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң документларның гамәлдә булу вакытлары чыгу яки мәгълүмат үзгәрү;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның урындагы затының, дәүләт хезмәткәренең, күпфукцияле үзәк хезмәткәренең, оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәк булган документларны беренче тапкыр кабул итүдән баш тартканда хаталык белән яки законга каршы гамәлләр кылуы (гамәл кылмавы) фактының документаль раслану очрагы. Гариза язучы бу турыда дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган җитәкчесе имзасы куелган хат белән искәртелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен аннан гафу үтенәләр. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган нормативхокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары | Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары | 681 номерлы карарның 6,7 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Гариза язучы яки аның вәкиле әлеге Регламентның 2.5 пунктында санап кителгән документларны тапшырмаганда | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Бәяләмә бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлеге турында Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (күләме, сроклары, сыйфаты)<br>б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән оешмалар хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы килешүләр буенча җәлеп ителгән эшчеләрнең) тиешле квалификацияләре (шул исәптән югары юридик белемнәре, юридик өлкәдә эшләү тәҗрибәләре) булмау;<br>в) бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә оешманың иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүенә бәйле рәвештә булган гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, аларның компетенцияләре буенча башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип | Кагыйдәләрнең 7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | табылган шикаятьләр булу;<br>г) оешма турындагы мәгълүматларның ачыклыгы һәм аларны карау мөмкинлегенең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (алар булган очракта);<br>д) бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән килешүләрне үтәү кысаларында хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәләре буенча гадел булмаган тәэмин итүчеләр реестрында оешма турында мәгълүмат булу;<br>е) салымнар һәм җыемнар буенча, Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу;<br>ж) дөрес булмаган мәгълүматлар тупланган документлар тапшыру яки тиешле тәртиптә тутырылмаган документлар тапшыру.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән<br>өчен алына торган дәүләт<br>пошлинасы яки башка төрле | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| түләүнең тәртибе,<br>күләме һәм<br>алу нигезләре | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте<br>күрсәткәндә, дәүләт<br>хезмәте<br>күрсәтү өчен зарури һәм<br>мәҗбүри булып торучы<br>алынучы түләүләрнең<br>тәртибе,<br>күләме һәм нигезләре,<br>андый<br>түләүнең күләмен<br>исәпләү<br>методикасы турында<br>мәгълүматны да кертеп | Кичектергесез һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү кирәкми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен<br>күрсәтү<br>турында запрос биргәндә<br>һәм<br>андый хезмәтләрне<br>күрсәтүнең<br>нәтиҗәсен алганда<br>чираткөтүнең максималь<br>срогы | Дәүләт хезмәтен алырга тиешле кешенең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүендә максималь вакыт 15 минут.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | 601 номерлы Указның 1 пунктының «д» пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада да | Гариза кергән көнне.<br>Гариза электрон формада ял (бәйрәм) көнне бирелгән очракта – ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналар һәм бүлмәләргә, гариза бирүчеләр көтеп утыра һәм кабул ителә торган урыннарга, шул исәптән әлеге объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртипләре турындагы күрсәтмә, текст рәвешендәге һәм мультимедия мәгълүматны урнаштыру | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br><br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга киртәләрсез керә алуы, шул исәптән бинага уңайлы керү-чыгу һәм бина чикләрендә уңайлы хәрәкәт тәэмин ителә.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы күрсәтмә, текст рәвешендәге һәм мультимедия мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урынга, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгәнлеген исәпкә алып урнаштырыла. | 181-ФЗ номерлы Федераль закон; 880 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | | |
| 2.15.Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең уңайлылык һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән чакта урындагы затлар белән үзара хезмәттәшлекләре саны һәм дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү эшенең барышы турында, шул исәптән | Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең уңайлылык күрсәткечләре булып торалар:<br>бина һәм бүлмәләрнең җәмәгать транспорты килеп җитә торган урында булулары;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бина һәм бүлмәләрнең инвалидлар өчен уңайлы булулары;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бина һәм бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br><br>дәүләт хезмәте күрсәтүнең алымнары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендә,<br>Министрлыкның рәсми сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталында тулы мәгълүмат бирелү;<br>гаризаны электрон вариантта бирү мөмкинлеге;<br>гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен уңайлылыгына бәйле булмаган, аларга хезмәтләрне башкалар белән тигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган башка киртәләрне үтүдә булышлык итү. | |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүматикоммуникация технологияләрен файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карау вакытлары саклану;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелүнең нәтиҗәләрен алу вакытлары саклану;<br>әлеге Регламентның Министрлык белгечләре тарафыннан бозылуына нигезле шикаятьләр булмау;<br><br>гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән аралашулары саны:<br><br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә - бер тапкырдан артык түгел (консультацияне исәпкә алмыйча); дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша юллаганда – юк (консультацияне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүче белән Министрлык белгеченең бер тапкыр үзара аралашуының дәвамлылыгы - 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәтләре, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша гамәлгә ашырылмый.<br><br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://minjust.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталында алынырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Министрлыкка 63-ФЗ номерлы һәм 210- ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза куелган электрон документлар рәвешендә дә юллана ала. | 63-ФЗ номерлы Федераль закон<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |

### 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкаруның составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында башкару

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы
3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризада җибәрелгән хаталарны төзәтү;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү эшендә катнаша торган органнарга ведомствоара запросларын формалаштыру һәм юллау;

5) бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белешмә проектын әзерләү;

6) гариза бирүчегә бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән белешмәне тапшыру;

7) техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентның 2 кушымтасында китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтү.

Гариза язучы дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефоннан яки почта (шул исәптән электрон почта) аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән мәрәҗәгать формасы һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булган очракта Бүлек белгече гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, бирелгән документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча җитешсезлекләрне күрсәтү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, гражданнарның консультация сорап мөрәҗәгать итүләрен мөрәҗәгатьләрне теркәү журналына теркәү (гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү).

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче Министрлыкның Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлегенә (алга таба – Оештыру бүлеге) гаризаны шәхсән китереп бирә.

Гариза шулай ук заказлы хат рәвешендә почта аша да җибәрелергә мөмкин.

Электрон формада җибәрелгән гариза 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә имзалана (раслана) һәм электрон күчергечләрдә һәм (яки) Интернет челтәрен дә кертеп, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат телекоммуникация челтәрләрен файдаланып тапшырыла.

Гариза Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да бирелергә мөмкин.

Заказлы хат рәвешендә почта аша яки электрон формада килгән гаризалар гомуми тәртиптә карала.

3.3.2. Оештыру бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

законлы вәкил яки дәүләт хезмәтләрен алучы затның вәкаләтле вәкиле сыйфатындагы гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән тиешле барлык документларның да бирелүен һәм аларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирүләрен тикшерүне. Тикшерү Бүлек белгече катнашында уздырыла.

Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Регламентның 2.8. пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен җирлек булган очракта белгеч гариза бирүчегә документларны кабул итү һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен җирлек булуы турында аңлата һәм документларны алудан баш тарту өчен табылган җирлек эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтара. Гариза бирүче таләбе буенча баш тарту очрагы язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза бирүче гаризаны һәм документларны почта аша (электрон почта аша) җибәргән очракта Оештыру бүлеге белгече аңа документларны, аларны алудан баш тарту өчен табылган җирлек эчтәлеген язмача аңлатып, почта (электрон почта) аша кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаганда Оештыру бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

гаризаның документлар кабул ителү көне, аның керү саны куелган күчермәсен гариза бирүчегә шәхсән тапшыруны яки электрон почта аша (аның теләге буенча) юллауны;

гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары документлары әйләнешенең “Электрон Хөкүмәт” бердәм ведомствоара системасы аша (алга таба - электрон документлар әйләнеше) электрон формада Татарстан Республикасы юстиция министрына (алга таба - министр) юллауны.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза кергән көнне башкарыла

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карар өчен министрның беренче урынбасарына юлланган гариза.

3.3.4. Министрның беренче урынбасары гаризаны карый һәм карар өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына юлланган гариза.

3.3.5. Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм гаризаны эшләү өчен аңа тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көннән бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшләү өчен Бүлек белгеченә юлланган гариза

3.4. Бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белешмә бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.4.1. Бүлек белгече:

гаризаны карый;

гариза бирүче Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) законнар нигезендә ведомствоара запросларны формалаштыра һәм юллый. Ведомствоара запрослар язма рәвештә кәгазь күчергечтә яки электрон документ формасында юлланалар;

аңлатма хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белешмә проектларын әзерли  һәм аларны килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза үтәү өчен Бүлек белгеченә юлланган көннән алып ундүрт көн эчендә башкарыла, әмма бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белешмә бирүнең әлеге Регламент белән билгеләнгән срогы тәмамланырга 10 көннән дә кимрәк вакыт калганчы түгел.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган аңлатма хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белешмә проектлары.

3.4.2. Бүлек башлыгы аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектларын тикшерә һәм аларны килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура күрсәтелгән проектлар килештерү өчен Бүлек башлыгына кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юлланган аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектлары.

3.4.3. Министрның беренче урынбасары аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектларын килештерә һәм аларны министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура күрсәтелгән проектлар килештерүгә кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән һәм карау өчен министрга кертелгән аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектлары.

3.4.4. Министр аңлатма хатын имзалый, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектларын килештерә.

Имзаланган аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы килештерелгән нигезле белешмә проектлары Оештыру бүлегенә юлланалар.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура күрсәтелгән проектлар килештерү өчен министрга кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган һәм теркәү өчен Оештыру бүлегенә бирелгән аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектлары.

3.4.5. Оештыру бүлеге белгече:

аңлатма хатын терки һәм бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы килештерелгән нигезле белешмә проектлары министр тарафыннан имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзалау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы килештерелгән нигезле белешмә проектлары.

3.4.6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмәне алганнан соң, Бүлек белгече аңлатма хаты проектын әзерли, аны бүлек башлыгы белән, Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары белән килештерә һәм аны имзалау өчен министрга юллый. Министр аңлатма хатын имзалый һәм аны Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмәне алганнан соңгы бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган һәм Бүлеккә юлланган аңлатма хаты.

3.4.7. Бүлек белгече:

гариза язучыны дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән искәртә, Оештыру бүлегенә бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә белән булган аңлатма хатын тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура аңлатма хаты министр тарафыннан имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәү өчен Оештыру бүлегенә тапшырылган аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә.

3.5. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен юллау.

3.5.1. Оештыру бүлеге белгече:

бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә белән булган аңлатма хатын терки һәм аны гариза язучыга гаризада күрсәтелгән ысул белән юллый (бирә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура аңлатма хаты министр тарафыннан имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза язучыга гаризада күрсәтелгән ысул белән юлланган (бирелгән) бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә белән булган аңлатма хаты.

3.6. Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гаризаны карау.

Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гариза әлеге Регламентның 3.3-3.5 пунктларында каралган тәртиптә теркәлә һәм карала.

3.7. Техник хатаны төзәтү

бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмәне кабат рәсмиләштерү алдан бирелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмәдә җибәрелгән техник хаталарны (хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хаталар) бетерү белән бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмәне кабат рәсмиләштерү ирекле формада язылган, әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсе аша бирелгән һәм теркәлгән мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) нигезендә гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгатькә гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән һәм хаталар булган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә, шулай ук, документлар гариза язучы вәкиле тарафыннан бирелгән очракта, гариза бирүче исеменнән

гамәллләр кылу вәкаләтенә ия булган затның вәкаләтләрен раслый торган ышаныч кәгазе кушып бирелә.

3.7.1. Оештыру бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

техник хатаны төзәтү турындагы мөрәҗәгатьне кабул итүне һәм электрон документлар әйләнеше системасында теркәүне;

мөрәҗәгатьне министрга электрон документлар әйләнеше системасында электрон формада юллауны.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган мөрәҗәгать.

3.7.2. Министр мөрәҗәгатьне карый һәм карау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен министрның беренче урынбасарына юлланган мөрәҗәгать.

3.7.3. Министрның беренче урынбасары мөрәҗәгатьне карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына юлланган мөрәҗәгать.

3.7.4. Бүлек башлыгы Бүлек белгечен билгели һәм мөрәҗәгатьне үтәү өчен аңа тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать Бүлеккә юлланган мизгелдән бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: үтәү өчен Бүлек белгеченә юлланган мөрәҗәгать.

3.7.5. Бүлек белгече:

аңлатма хатын, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектын әзерли;

аңлатма хатын, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура  мөрәҗәгать үтәү өчен Бүлек белгеченә юлланган көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган аңлатма хаты, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты.

3.7.6. Бүлек башлыгы әзерләнгән аңлатма хатының, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектының дөреслеген тикшерә, аны килештерә һәм килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура  аңлатма хаты, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты килештерү өчен Бүлек белгеченә кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юлланган аңлатма хаты, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты.

3.7.7. Министрның беренче урынбасары аңлатма хатын, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектын килештерә һәм аларны министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура  аңлатма хаты, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты Бүлек башлыгыннан кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм карау өчен министрга юлланган аңлатма хаты, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты.

3.7.8. Министр аңлатма хатын имзалый, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектын килештерә.

Имзаланган аңлатма хаты, килештерелгән кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты Оештыру бүлегенә юллана.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура  күрсәтелгән проектлар килештерү өчен министрга кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган һәм теркәү өчен Оештыру бүлегенә юлланган аңлатма хаты, килештерелгән кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты.

3.7.9. Оештыру бүлеге белгече:

аңлатма хатын терки һәм кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура  министр тарафыннан аңлатма хаты имзаланган һәм кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проекты килештерелгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзалау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган аңлатма хаты, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмәнең килештерелгән  проекты.

3.7.10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары тарафыннан имзаланган кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмәне алганнан соң, Бүлек белгече аңлатма хаты проектын әзерли,  аны бүлек башлыгы, министрның беренче урынбасары белән килештерә һәм имзалау өчен министрга юллый.  Министр аңлатма хатын имзалый һәм аны Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура  Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары тарафыннан имзаланган кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмәне алганнан соңгы бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган һәм Бүлеккә юлланган аңлатма хаты.

3.7.11. Бүлек белгече:

Гариза бирүчене техник хатаны төзәтү турындагы мөрәҗәгатьтә яки дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан фадаланып, документның әзерлеге турында түбәндәге ысулларның берсе аша искәртә:

гариза язучы аларны шәхсән алырга теләк белдергән очракта, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тартуны мотивлаштырылган нигезләүне бирү көнен һәм вакытын хәбәр итә;

гариза язучы аларны шәхсән алырга теләк белдермәгән очракта, кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тартуны мотивлаштырылган нигезләү аңа бүлек белгече тарафыннан почта аша яки булган элемтә каналлары буенча электрон рәвештә юллана.

Аларны тапшыру ысулын билгеләгәннән соң, бүлек белгече кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тартуны мотивлаштырылган нигезләүне, аңлатма хатын теркәү өчен Оештыру бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура  министр тарафыннан аңлатма хаты имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тартуны мотивлаштырылган нигезләү белән булган теркәлгән аңлатма хаты. Гариза язучы белән кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тартуны мотивлаштырылган нигезләүне алу ысулын килештерү.

3.7.12. Оештыру бүлеге белгече гариза бирүченең теләге буенча кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тартуны мотивлаштырылган нигезләү белән бергә аңлатма хатын гариза бирүчегә шәхсән тапшыра яки гаризада күрсәтелгән адрес буенча юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура министр аңлатма хатын имзалаган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза язучыга юлланган (бирелгән) техник хата төзәтелгән кабат рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә.

3.8.  Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне  контрольдә тоту формалары һәм тәртибе

4.1. Министрлыкның урындагы затлары тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның сакланышын һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшерүдә тоту әлеге административ процедураның үтәлеше өчен җаваплы зат һәм министрның дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эшләрне оештыру өчен җаваплы урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлылыгын тикшерүдә тоту үз эченә тикшерүләр үткәрүне, карарларны карау һәм кабул итүне, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы урындагы затларның гамәлләренә (гамәлләр кылмауларына) шикаять белдергән мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне тикшерүдә тоту формалары булып тикшерү уздыру тора:

эш башкаруны алып баруга;

документларны карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүенә;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклауга;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен саклауга.

Тикшерүләрне башкаруның кабатланучанлыгы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм плансыз (гариза бирүченең анык мөрәҗәгате буенча) рәвештә башкарыла.

4.2. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очрагы ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм гаепле дип табылган затлар, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.

4.3.Дәүләт хезмәтләре күрсәтелүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшерүдә тоту Министрлыкның дәүләт хезмәтләре күрсәтүдәге эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүматлар алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, шулай ук аның урындагы затларының һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең кылган (кылмаган) гамәлләренә, шулай ук кабул иткән карарларына судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар Министрлыкның, шулай ук Министрлыкның урындагы затларының яки Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге тәртиптә - Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклылар. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар яки мәгълүмат яки гамәлләр кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүчедән документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллекләре күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, яки дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта кирәкле булган документлар яки мәгълүмат таләп итү, “Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

5.3. Шикаять кәгазь күчергечтә язма рәвештә яки электрон формада бирелә.

Министрлыкның, шулай ук Министрлыкның урындагы затларының яки Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең министрның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты аша, Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы аша, шулай ук гариза язучыны шәхсән кабул иткәндә бирелергә мөмкин.

5.4. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган Министрлыкның, Министрлыкның урындагы затының яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең исемен;

2) гражданинның – физик затның – фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, яки мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче мөрәҗәгать итүченең – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның урындагы затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) дәүләт хезмәте алучының Министрлыкның, аның урындагы затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләр.

Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (алар булганда), яки аларның күчермәләре бирелә.

5.5. Дәүләт хезмәтен алучы шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы.

5.6. Шикаятьне карау срогы – ул теркәлгән көннән соңгы 15 эш көне эчендә. Ә Министрлыкның, Министрлыкның урындагы затының гариза язучыдан документларны алудан яки җибәрелгән хәреф хаталарын төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта, яки андый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылуга шикаять белдерелгән очракта - шикаять теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән хаталарны төзәтү, гариза язучыга аларны алу Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару формаларында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Гариза язучыга әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма формада һәм гариза язучының теләге буенча, электрон формада да, шикаять каралу нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

5.7[1]. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта табылган җитешсезлекләрне кичектергесез рәвештә бетерү максатыннан, гариза язучыга Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп чыккан уңайсызлыклар өчен гафу үтенеп, гариза язучыга дәүләт хезмәтен алу өчен алга табаниләр эшләргә кирәклеге аңлатыла.

5.7[2]. Шикаять канәгатьләндерелә алмый торган дип табылган очракта, гариза язучыга җавапта шундый карар кабул ителү сәбәпләре турында нигезләнгән аңлатмалар, шулай ук әлеге карарга шикаять белдерү тәртибе турындагы мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы ачыкланган очракта шикаятьләрне карау буенча урындагы зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы юстиция министрына

____________________________________
оешма исеме, адресы (почта һәм (яки) электрон), телефон номеры (булганда)

ГАРИЗА

Сездән социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма

________________________________________________________________________
(социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма исеме)

тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең

________________________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәт аталышы)

билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүегезне үтенәм.

Оешманың чит дәүләт агенты функцияләрен башкаручы коммерцияле булмаган оешма түгеллеген, һәм бер ел һәм аннан артыграк вакыт дәвамында иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары белән расланга критерийларына туры килә торган санап кителгән иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүен раслыйбыз:

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына туры килүе һәм аның эчтәлегенә таләпләр
(күләме, сроклары, күрсәтү сыйфаты)

(иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы килешүләр нигезендә җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) тиешле квалификациягә (шул исәптән профессиональ белемгә, бу өлкәдә эш тәҗрибәсенә) ия булулары, мондый затларның тиешле күләмдә булулары)

(бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә иҗтимагый файдалы хезмәтләр алучыларның аларны күрсәтү сыйфатыннан канәгать булулары (оешманың иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү белән бәйле гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, аларның компетенцияләре чикләрендә башка органнар тарафыннан нигезләнгән шикаятьләр булмау)

(коммерцияле булмаган оешма турындагы мәгълүматның ачыклыгы)

(бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә оешманың «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешүләрне үтәү кысаларында хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәләре буенча гадел булмаган тәэмин итүчеләр реестрында тормавын раслау )

Раслаучы документлар өстәп бирелә:

1. ____________________
2. ____________________
3. ____________________

һәм башкалар.


(Вазыйфа) (Имза) (Ф.И.Ә.и.)

«___»____________20__г.

М.У. (булганда)

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

# ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТКӘНДӘ ГАМӘЛЛӘР ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕНЕҢ БЛОК-СХЕМАСЫ



Бүлек белгече

Гаризаны карый, гариза бирүче Регламентның 2.6 пунктында бирелгән документларны бирмәгәндә,дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) законнар нигезендә запрослар юллый.
Ведомствоара запрослары язма рәвештә кәгазь күчергечтә яки электрон документ рәвешендә юлланалар.
Аңлатма хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектларын әзерли

Аңлатма хатының, бәяләмәнең яки аны бирүдән баш тарту турында нигезле белешмә проектлары

Бүлек башлыгы

Проектларның, аңлатма хатының, бәяләмәнең яки аны бирүдән баш тарту турында нигезле белешмәнең дөреслеген тикше

Килештерелгән документлар

Министрның беренче урынбасары

Әзерләнгән проектларны килештерә

Килештерелгән проектлар

Министр

Әзерләнгән проектларны килештерә, аңлатма хатын имзалый

Килештерелгән документлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллана

Имзаланган документлар

Бүлек белгече

Аңлатма хаты проектын әзерли. Аны бүлек башлыгы, министрның беренче урынбасары белән килештерү һәм имзалау өчен министрга юллый

Министр

Аңлатма хатын имзалый

Бүлек белгече

Аңлатма хатын, бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белешмәне Оештыру бүлегенә тапшыра

Теркәүгә тапшырылган документлар

Оештыру бүлеге белгече

Документларны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе турында гариза бирүчегә бирелгән бәяләмә

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр
сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре
турындабәяләмәләр бирүдән баш тарту турында
нигезле белешмә

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан уздырылган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча, социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннанкүрсәтелә торган

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешманың тулы исеме һәм төп дәүләт теркәлү номеры)

түбәндәге иҗтимагый социаль файдалы хезмәтләрнең:
_____________________________________________________________________________;
_____________________________________________________________________________;
_____________________________________________________________________________.

(иҗтимагый файдалы хезмәт аталышы)

билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында белешмә бирүдән баш тарта.

Әлеге иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатыныңбилгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләр буенча туры килмиләр:
_____________________________________________________________________________;
_____________________________________________________________________________;
_____________________________________________________________________________.

(критерийларга туры килмәве күрсәтелә)

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта
(белешмәлек)

# СОЦИАЛЬ ОРИЕНТЛАШКАН КОММЕРЦИЯЛЕ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН ИҖТИМАГЫЙ ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ БИЛГЕЛӘНГӘН КРИТЕРИЙЛАРГА ТУРЫ КИЛҮЛӘРЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘЛӘР БИРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ УРЫНДАГЫ ЗАТЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 292-00-70 | minjust@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 8(843) 223-06-64 | Aynur.Galimov@tatar.ru |
| Оештыруэшеһәмдокументларәйләнешебүлеге башлыгы | 8(843) 223-07-60 | Farida.Nurieva@tatar.ru |
| Түләүсезюридикярдәмкүрсәтү неоештыруһәмпланлаштырубүлегебашлыгы | (843) 292-26-96<br>(843) 223-09-43 | Aleksandr.Lohotskoy @tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес | Сайт |
|---|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһ., Ирек мәйданы, 1 йорт | Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы | (843) 264-77-46 | pisma@tatar.ru | www.prav.tatarstan.ru |